**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

15 сентября 2026 ел — № 57

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әтнә район Советының 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 135 статьясындагы өченче өлеше, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Әтнә районы прокуратурасының 07.08.2026 №02-08-02-2026/Прдп 331-26 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 мартындагы 120 номерлы Әтнә район Советы карарына (Әтнә район Советының 18.11.2022 №144, 27.01.2023 №167, 15.05.2024 №228, 16.11.2024 №245, 04.02.2025 №260, 25.04.2025 №275 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. V бүлекнең 3нче пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткәргә яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затка дисциплинар җинаять кылган өчен дисциплинар түләтү кулланылуга бәйле рәвештә премия күләмен киметү аңа тиешле дисциплинар түләтү кулланылган чорда исәпләнә торган хезмәт хакы составына керүче премияләргә карата гына гамәлгә ашырыла.»;

1.2. V бүлекнең 4нче пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль хезмәткәрне яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затны дисциплинар җаваплылыкка тартуга бәйле рәвештә премия күләменең кимүе айлык хезмәт хакы күләменең 20 проценттан артыгракка кимүенә китерә алмый.»;

1.3. V бүлекнең 5нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга:

http://atnya.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әтнә муниципаль районының финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы Рәисе Р.Ш. Хисамиев